Важашур авыл җирлеге башлыгы карары

12 гыйнвар, 2024 ел №1

Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февральындагы 4 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Важашур авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына, Важашур авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февральындагы 4 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Важашур авыл җирлеге Советы карарының кушымта итеп бирелгән проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыру комитетын түбәндәге составта төзергә:

- Иванов Петр Леонидович
- Кузнецова Анжелла Андреевна
- Усманов Фаниль Хасанович
- Синин Владислав Михайлович
- Акманаев Александр Пантелеймонович

2. Оештыру комитетына 2024 елның 13 гыйнварыннан 2024 елның 7 февраленә кадәр экспозиция һәм җыелыш үткәрү аша гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрүне 2024 елның 7 февраленә 14.00 сәгатьтә ТР, Кукмара районы, Починок Сутер авылы, Яшьләр урамы, 1д йорты адресында урнашкан мәдәният йорты бинасында билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты экспозициясен 2024 елның 13 гыйнварыннан 2024 елның 7 февраленә кадәр Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Починок Сутер авылы, Яшьләр урамы, 1д йорт адресында урнашкан Важашур авыл башкарма комитеты бинасында уздырырга.

5. Экспозициягә килүчеләргә экспозиция урнаштыру урыны буенча түбәндәге график буенча консультация үткәрергә: сишәмбе, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә 9.00 сәгатьтән 11.00 гә, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда.

6. Билгеләргә:

- Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февральындагы 4 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Важашур авыл җирлеге Советы карары проекты Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru// веб-адресы буенча 2024 елның 12 гыйнварыннан да соңга калмыйча урнаштырыла;

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар 2024 елның 6 февраленә кадәр Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Починок Сутер авылы, Яшьләр урамы, 1д йорт адресында урнашкан оештыру комитетына язма рәвештә, шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында язмача һәм телдән кертә алалар.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча, Важашур авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов

Проект

Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

______________, 2024 ел №

Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февральындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Важашур авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Важашур авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февралендагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (Важашур авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрьендэге 34номерлы, 2018 елның 22 июнендэге 14 номерлы , 2019 елның 20 февралендэге 4 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 13 номерлы, 2021 елның 20 декабрендэге 38 номерлы, 2022 елның 28 январындагы 1 номерлы, 2022 елның 8 сентябрьындагы 18 номерлы 2023 елнын 24 июлендагы 15 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 30 нчы статьяның 2 нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:

«- территориаль планлаштыру документларында булган торак пунктлар чикләренең (шул исәптән торак пункт (торак пунктлар) чикләренең җир кишәрлекләре чикләре белән киселеше ачыкланган очракта) урнашуы турындагы мәгълүматларның Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында күрсәтелгән торак пунктлар чикләре урнашуының торак пунктлар чикләре турында мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына керткәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән тасвирламасына туры килмәве;»

1.2. 32 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Территориаль зоналар чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен кисеп үтә алмый (Россия Федерациясе Җир кодексында яки башка федераль законда каралган очракларда территориаль зоналар чикләрен кисеп чыга алган җир кишәрлегеннән тыш). Территориаль зоналарның чикләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган территорияләрне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләре, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре, федераль әһәмияттәге тарихи торак пунктлар территорияләре чикләре, төбәк әһәмиятендәге тарихи торак пунктлар территорияләре чикләре белән кисү рөхсәт ителә.";

1.3. 35 статьяның 1 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналар

1. Торак зоналар күп катлы торак йортлар, кече һәм урта катлы торак йортлар, шәхси торак йортлар төзү өчен билгеләнгән.

2. Рөхсәт ителгән төп кулланылыш объектлары территориянең кимендә 60 % ын биләргә тиеш. Территориянең 40 % ына кадәр рөхсәт ителгән куллануның төп төрләренә карата ярдәмче объектларны урнаштыру өчен кулланырга рөхсәт ителә.

Ж-1. Шәхси торак йортлар төзелеше зонасы

Ж-1 шәхси торак йортлар төзү зонасы йорт яны җир кишәрлекләре белән яки алардан башка, җирле әһәмияттәге хезмәтләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы белән аерым торучы һәм блокланган шәхси торак йортлардан (коттеджлардан) торак районнар формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.

Шәхси торак төзелеше зонасы түбәндәгеләрне урнаштыру өчен билгеләнгән:
- йорт яны җир кишәрлекләре булган аерым тора торган торак йортлар;
- шәхси торак төзелеше;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару;
- блокланган торак йортлар;
- аз катлы күп фатирлы торак йортлар (дүрт катка кадәр, шул исәптән мансардалы).

Торак зоналарда физик һәм юридик затларны түбәндәге коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүче биналарны һәм корылмаларны урнаштыру рөхсәт ителә: су, җылылык, электр, газ белән тәэмин итү, канализация агынтыларын чыгару, күчемсез милек объектларын (котельняларны, су алу башняларын, чистарту корылмаларын, насос станцияләрен, суүткәргечләрне, электр тапшыру линияләрен, трансформатор подстанцияләрен, газ

үткәргечләрен, элемтә линияләре, телефон станцияләрен, канализацияләр, тукталышлар, урып-җыю һәм авария техникасына хезмәт күрсәтү өчен гаражлар һәм мастерскойларны, кар җыю һәм эретү өчен корылмаларны) чистарту һәм җыештыру.

Рөхсәт ителгән файдаланунының ярдәмче төрләре:

- аерым тора торган яки торак йортларга кертеп төзелгән гаражлар яки ачык автостоянкалар: Шәхси кишәрлеккә 2 машина урыны;
- кечкенә үлчәмле судноларны саклау өчен гаражлар;
- хуҗалык, йорт яны корылмалары;
агач бакчалары, яшелчә бакчалары, алгы бакчалар;
- теплицалар, оранжереялар;
- гомуми мәйданы 150 кв. м. дан артмаган беренче кирәкле товарлар кибетләре;
- даруханәләр;
- гомуми мәйданы 600 кв. метрдан артмаган амбулатор-сырхауханә учреждениеләре;
- су саклау өчен махсус резервуарлар;
- су алу өчен скважиналар, шәхси коелар (җир асты суларының саклану дәрәҗәсенә карап, кимендә 30 һәм 50 м аралыкта санитар саклау зонасын оештыру шарты белән);
- шәхси бассейннар;
- шәхси мунчалар, сауналар, ишегалды бәдрәфләре;
- янгыннан саклану объектлары (гидрантлар, резервуарлар, янгынга каршы сулыклар);
- ашлама саклау мәйданчыклары, тирес мәйданчыклары, чокырлары яки тартмалары;
- чүп җыю мәйданчыклары.

Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре:
- биеклеге 4 каттан артмаган, фатир яны кишәрлекләре булган яки алардан башка аз катлы күп фатирлы торак йортлар;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр;
- кер юу һәм химик чистарту кабул итү пунктлары;
- күп дигәндә 20 урынлык кунакханәләр;
- вакытлыча сәүдә объектлары;
- офислар, банк бүлекчәләре;
- клублар (мәдәният йортлары);
- китапханәләр;
- дини объектлар;
- фельдшер-акушерлык пунктлары, шул исәптән модульле;
- терлек һәм кош-корт асрау өчен корылмалар (күршеләр белән дустанә мөнәсәбәтләр сакланса);

- хайваннарны даими асрамый торган ветеринария лечебницалары;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- спорт заллары, рекреация заллары;
- эш вакыты чикләнгән күп максатлы һәм махсус куллану клублары;
- полиция бүлекләре, участок пунктлары;
- элемтә бүлекчәләре;
- торак-эксплуатация оешмалары һәм авария-диспетчерлык хезмәтләре;
- хезмәт күрсәтү һәм коммерция куллану объектлары алдында машина кую урыны;
- кәрәзле, радиорелеле һәм спутник элемтәсе антенналары;
- кабул итү пунктлары һәм вак көнкүреш ремонты (аяк киеме, кием, зонтлар, сәгатьләр һ. б. ремонтлау) остаханәләре;
- 100 кв. м. кадәр тегү ательелары һәм остаханәләре;
- чәчтарашханә, косметика салоны, матурлык салоны;
- үз ихтыяҗлары өчен гаражлар;
- автомобильләрне ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән остаханәләр;
- автомобиль юу урыннары;
- кибетләр;
- һәйкәлләр һәм истәлекле билгеләр.

Җир кишәрлекләренең зурлыгы һәм рөхсәт ителгән төзелеш параметрларының чик кыйммәтләре әлеге бүлеккә аларны эшкәртүгә карап кертеләчәк. Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларын эшләгәнче, аларны билгеләү җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планының тиешле бүлеге белән башкарыла.

Ж-1П. Перспективалы торак төзелеше зонасы

Перспективалы торак төзелеш зонасы Кукмара муниципаль районы һәм ______________ авыл җирлегенең территориаль планлаштыру документларына ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге хезмәтләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы белән аерым торган шәхси йортлар белән планлаштырылган төзелеш өчен бүлеп бирелгән.

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре, рөхсәт ителгән файдалануның чик параметрлары, Ж-1П зонасы өчен җир кишәрлекләрен төзүгә таләпләр җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләренә, Ж-1 зонасы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен төзүгә чик параметрларына һәм таләпләренә туры килә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов